| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.03.2023 г. Казань № 35/2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 10.07.2020 №262/2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 22.12.2020 №718/2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 22.10.2021 №594/2021;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 04.02.2022 №27/2022.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының _____ елның «__» ______ _________ номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче, оешу-хокук формасына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар яки шәхси эшкуарлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү (алга таба – бәяләр (тарифлар) билгеләү).

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты)

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша гамәлгә ашырылмый.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар, бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту турында хат-белдерү, бәяләрне (тарифларны) билгеләүдән баш тарту һәм тәкъдим ителгән документларны һәм материалларны кире кайтару турында хат-белдерү.

2.3.2. Дәүләт комитетының бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы карары реквизитлары:

бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

вәкаләтле затның имзасы.

2.3.3. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту турында хат-белдерү реквизитлары:

бәяләрне (тарифларны) билгеләүдән баш тарту турында хатның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

вәкаләтле затның имзасы яки электрон имза турында мәгълүмат.

2.3.4. Бәяләр (тарифлар) билгеләүдән баш тарту турында хат-белдерү реквизитлары:

бәяләрне (тарифларны) билгеләүдән баш тарту турында хатның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

вәкаләтле затның имзасы яки электрон имза турында мәгълүмат.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Портал) шәхси кабинетына җибәреп.

2.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларында теркәлми.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте җайга салуның чираттагы хисап чоры башланыр алдыннан Дәүләт комитеты тарафыннан гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, электрон документлар әйләнеше системасы, Татарстан Республикасында Ягулык-энергетика комплексы һәм торак-коммуналь хуҗалык оешмалары тарифларын фаразлау һәм анализлауның бердәм мәгълүмати-аналитик системасы аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Дәүләт комитеты тарафыннан гариза әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган җайга салуның чираттагы хисап чоры башланыр алдыннан елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Порталдагы шәхси кабинет аша тапшырылган очракта, Дәүләт комитеты тарафыннан Порталдагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган гаризага эш номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә номер бирелгән көннән алып, бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган чираттагы исәп-хисап чоры башланганчы елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.2. Үзенә карата бәяләр (тарифлар) элегрәк дәүләт тарафыннан җайга салынмаган оешма өчен агымдагы елга бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдим агымдагы елның 1 ноябреннән соңга калмыйча тапшырылган очракта билгеләнә. Бу очракта оешма өчен тарифлар бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим һәм кирәкле нигезләү материаллары Дәүләт комитетына тулы күләмдә алынган көннән башлап 30 календарь көн эчендә билгеләнә. Дәүләт комитеты карары буенча күрсәтелгән срок 30 календарь көннән дә артмаска тиеш. Дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары әлеге Административ регламентның 2.4.1 пунктында билгеләнгән.

2.4.3. Идарә (коллегия) утырышы нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитеты «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 08 августындагы 808 номерлы карары белән каралган Җылылык челтәрләре милекчеләрен яисә башка законлы хуҗаларын җылылык челтәре оешмаларына кертү критерийларына туры килмәгән очракта, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында

тәкъдимнәр кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә бәяләр (тарифлар) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Порталда, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар;

Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдим оешманың бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гаризасыннан (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта) һәм кирәкле нигезләү материалларыннан тора.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гаризага түбәндәге документлар һәм материаллар теркәлә:

а) эшчәнлекнең җайга салына торган төрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган, үзләренә карата хокуклар Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән (мондый хокуклар әлеге реестрда теркәлгән очракта, әлеге биналар, төзелмәләр, корылмалар, җир кишәрлекләре турындагы белешмәләр тапшырыла) күчемсез объектларга (биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, җир кишәрлекләренә) карата милекчелек хокукын, башка төрле законлы хокукны раслый торган хокук билгеләүче документларның күчермәләре (граждани-хокукый килешүләрнең, концессия килешүләренең күчермәләре, юридик зат үзгәртеп корылган очракта, – тапшыру актларының күчермәләре);

г) алдагы җайга салуның алдагы хисап чорына һәм соңгы хисап датасы өчен бухгалтерлык һәм статистик хисаплылык күчермәләре;

Бухгалтерия хисаплылыгы гаризага, әгәр ул «Хисапчылык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясында каралган хисапчы (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсында булмаса, теркәлә. Җайга салына торган оешма хисапчы (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында, хисапчылык хисабын бирсә, җайга салу органы ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып, әлеге дәүләт мәгълүмат ресурсыннан шундый хисап ала;

в) җылылык энергиясе (егәрлеге), җылылык китерү матдәсе, челтәрләр буенча тапшыруга кайнар су чыгымнары (югалтулар) күләмен, шул исәптән «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Җылылык белән тәэмин итү турында» федераль закон) нигезендә төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә, якларның килешүе белән билгеләнгән бәяләр буенча җылылык энергиясен (егәрлеген), җылылык китерү матдәсен китертү күләмен нигезләп, төрләр буенча дифференциацияләп, җылылык энергиясен (егәрлеген), җылылык китерү матдәсен нәтиҗәле җибәрү исәпләмәсе. Ресурсларны нәтиҗәле җибәрү исәпләмәсендә халыкка һәм аңа тиңләштерелгән

кулланучылар категорияләренә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә товарларга һәм хезмәтләр күрсәтүгә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) буенча җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен сатыла торган җылылык энергиясе (егәрлеге), җылылык китерү матдәсе күләме чагылдырыла;

г) җайга салуның алдагы хисап чорына һәм хисап чорына кулланыла торган ягулыкның структурасы һәм бәяләре, шулай ук аның калориялелегә һәм аны китертү (ташу) хакы турындагы белешмәләр;

д) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлектән чыгымнар һәм кирәкле тулай табыш исәпләмәсе, Россия Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы нигезендә эшләнгән Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр (алга таба – методик күрсәтмәләр) нигезендә әзерләнгән икътисадый нигезләү (кулланыла торган индексларны, нормаларны һәм исәпләмә нормативларын, тарифларны җайга салу буенча тәкъдим ителә торган методны, озак сроклы җайга салу буенча тәкъдим ителә торган билгеләрне, җылылык белән тәэмин итү схемасында (ул расланган очракта) кабул ителгән чагыштырма үзгәрүчән чыгымнарны күрсәтеп) теркәп);

е) бәяләр (тарифлар) исәпләмәсе;

ж) билгеләнгән тәртиптә расланган инвестиция программасы күчермәсе (яки инвестиция программасы проекты), заем капиталын турыдан-туры финанслау һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле акчаларга булган ихтыяҗны нигезләп һәм, әгәр инвестиция программасын раслау «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы федераль законда каралган булса, инвестиция программасын финанслау чыганакларын күрсәтеп;

з) җайга салуның алдагы хисап чорында керми кала торган яки өстәмә алынган, рәсми статистик һәм бухгалтерлык хисаплылыгы яисә җайга салынулы оешмаларның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре нигезендә, шулай ук сатулар уздыру нәтиҗәсендә төзелгән килешүләр нигезендә ачыкланган керемнәр исәпләмәсе (әгәр тарифларның җайга салу методында башкача каралмаган булса);

и) мөрәҗәгать итүче тарафыннан сатулар үткәрүне раслый торган документларның күчермәләре (сатулар үткәрү турында нигезләмә, белдерү, документлар, сатулар үткәрү барышында төзелә торган беркетмәләр);

к) җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләр (шулай ук җылылык белән тәэмин итү килешүләренең, һәм (яки) җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтү турындагы килешүләрнең, һәм (яки) җылылык энергиясен (егәрлеген) һәм (яки) җылылык китерү матдәсен китертү килешүләренең, һәм (яки) резервлы җылылык егәрлеген саклап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү килешүләренең, һәм (яки) тоташтыру турындагы килешүләрнең) исемлеге, анда килешү төзелгән зат турында, килешү предметы, килешүне төзү датасы, килешүнең гамәлдә булу срогы, килешү буенча гамәлгә ашырыла торган товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) күләме,

кулланыла торган җылылык китерү матдәсенең төре һәм параметрлары турында мәгълүматлар чагылдырылырга тиеш;

л) ышаныч кәгазеннән башка гына оешма исеменнән эш итәргә хокуклы затны билгеләү турындагы документ күчермәсе;

м) дәүләт яки муниципаль милектәге җылылык белән тәэмин итү объектларына карата концессия килешүе буенча яклар килешүе нигезендә яки, җирлекне, шәһәр округын җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарына керткәнчегә кадәр, әлеге объектларның аренда килешүе нигезендә җитештерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә), шул исәптән электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында да, ике ставкалы тариф сайлау турында гариза, әлеге концессия килешүендәге (аренда килешүендәге) якларның җитештерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә), шул исәптән электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында да, тариф төрен бер ставкалыдан икен ставкалы тарифка үзгәртүгә ризалыгын раслый торган документларны теркәп;

н) җылылык челтәрләре хуҗасының җылылык челтәрләренә кертү критерийларына туры килүен раслаучы документлар күчермәләре һәм башка мәгълүмат;

о) «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюю турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карарының 66 пунктындагы алтынчы абзацы (алга таба - Бәяләү нигезләре) нигезендә җайга салына торган оешма тарафыннан узган җайга салу чорында ирешелгән чыгымнарны экономияләү барлыкка килүен нигезләүче һәм су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең план күрсәткечләренә ирешүен һәм расланган инвестиция программасына кертелгән чараларны гамәлгә ашыруны (шул исәптән билгеләнгән тәртиптә төзәтелгән) раслый торган күрсәткечләргә ирешүне раслаучы материаллар;

п) Бәя билгеләү нигезләренең 66 пунктының җиденче абзацына ярашлы рәвештә җайга салу оешмасы тарафыннан ирешелгән чыгымнарны экономияләүне раслаучы материаллар.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар алу каралмаган.

2.6.3. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гариза җайга салынулы оешманың җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан имзалана, җайга салынулы оешманың мөһере (ул булган очракта) белән таныклана һәм теркәлә торган документлар һәм материаллар исемлеген үз эченә ала.

2.6.4. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы эшне ачу өчен әлеге Административ регламент буенча күрсәтелгән документлар һәм материалларның тулы исемлеге.

2.6.5. Төгәлләштерелә торган оешма үз инициативасы белән Дәүләт комитетына агымдагы елның 1 декабренә кадәр бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимнәргә өстәмә материаллар, әмма Дәүләт комитеты идарәсе (коллегия) утырышы уздырган көнгә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул ителә торган өстәмә материаллар

тапшырырга хокуклы, ә бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар кабул ителгән очракта, элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар өчен җайга салуның агымдагы чорына бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр 14 календарь көннән дә соңга калмыйча.

2.6.6. Гаризага теркәп тапшырыла торган документлар һәм материаллар төп нөсхәдә яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәләрдә тапшырыла.

Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу - рөхсәт ителми.

2.6.7. Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.8. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдим җайга салу оешмасы тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тәкъдим ителергә мөмкин:

шәхсән җайга салына торган оешма җитәкчесе тарафыннан (мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан, әлеге затка оешма исеменнән ышанычнамәсез эш итәргә хокук бирә торган ышанычнамә яисә документ нигезендә);

кушып тапшырылганнарның исемлеге белән һәм кулга тапшыру тамгасы белән почта аша җибәреп.

2.6.9. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдим шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, электрон документлар әйләнеше системасы, ТР БМАС, Татарстан Республикасы рәсми порталының интернет-кабул итү системасы, Портал аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml – формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt – формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods – исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg – формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне (булган очракта), бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.6.10. Дәүләт комитеты, чираттагы җайга салу чорына кадәр, елның 1 маена кадәр, тарифларны җайга салу органына бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим кертә.

2.6.11. Агымдагы елга бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракта, элек бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешма өчен тарифлар билгеләү турындагы тәкъдим мондый оешма тарафыннан агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

2.6.12. Моңа кадәр үзенә карата бәяләргә (тарифларга) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешма өчен бәяләр (тарифлар) билгеләнгәндә, шулай ук җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә аерым оешмалар гамәлгә ашыра торган җайга салынулы эшчәнлекнең аерым төрләренә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракта, элегрәк аларга карата бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмый торган булса, әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының «г», «ж», «з», «и», «к», «о» һәм «п» пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырылмый.

2.6.13. Берләштерү, үзгәртеп кору яки тоташтыру формасында юридик затларны үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән җайга салуны оешма өчен бәяләр (тарифлар) билгеләнгәндә әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктының «а», «б», «и» һәм «к» пунктчалары нигезендә үзгәртеп корылган оешмага (үзгәртеп корылган оешмаларга) карата тапшырылган документлар һәм материаллар кулланылырга мөмкин.

Юридик затларны берләштерү яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән җайга салынулы оешма тарафыннан шулай ук мондый оешманың дәүләт теркәвенә алу датасына бухгалтерлык хисабы тапшырыла.

2.6.14. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм материаллар тапшыру каралмаган.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

бәяләр билгеләү (тарифлар) турында гаризага җайга салына торган оешманың җитәкчесе яисә башка вәкаләтле заты булмаган зат имза салган очракта;

гаризага теркәлгән документлар исемлеге булмаганда;

җайга салу оешмасының мөһере булмаганда (җайга салу оешмасында фактта булган очракта).

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Порталда, Дәүләт комитетының рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

2.8.2.1. бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим бирү срокларын үтәмәү;

2.8.2.2. мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы карары (алга таба – Җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләре) белән расланган Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләрендә каралган җылылык челтәре оешмалары милекчеләрен яисә башка законлы хуҗаларын җылылык челтәре оешмаларына кертү критерийларына туры килмәве.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Югарыда күрсәтелгән көтү вакытына төшке аш вакыты һәм эш вакыты булмаган вакыт кертелми.

Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Гаризаны Портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Порталдагы шәхси кабинетта һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – Объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

б) территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый Объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

в) Объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга Объектларда ярдәм күрсәтү;

д) инвалидларның Объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләреннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

е) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июлендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, Объектларга сукырларны озата йөри торган этне кертү;

з) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

и) инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;

к) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган

каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2.12.4. 2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламент бозылу очракларына карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.2. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Порталда тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләреннән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү;

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Порталдан алынырга мөмкин.

2.13.5. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Гаризаны электрон документ рәвешендә Портал (http://uslugi.tatarstan.ru) аша тапшыру мөмкинлеге бар.

2.14.3. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Порталда урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Порталдан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Портал, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.4. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Порталда БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Порталда шәхси кабинетка Дәүләт комитеты җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.5. Җайга салу оешмаларын Дәүләт комитетына кабул итүгә язу гамәлгә ашырылмый.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланылмый.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Дәүләт комитеты рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) һәм Порталда (http://uslugi.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җентекле рәвештә язмача аңлатып бирә һәм законнарда билгеләнгән срок эчендә

мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.14.8. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча гариза төзү өлешендә дә;

2) бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдимне кабул итү һәм теркәү;

3) бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы эшне ачу яки тәкъдимне караудан баш тарту һәм килгән тәкъдимне карау буенча эш буенча вәкаләтле кешене билгеләү турында карар кабул итү;

4) җайга салу ысулын сайлау турында карар кабул итү;

5) бәяләрне (тарифларны) исәпләү һәм бәяләр (тарифлар) исәпләмәсен җайга салу оешмасына юллау;

6) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында алынган тәкъдимгә экспертиза;

7) башкарылган алдан исәпләү нәтиҗәләре буенча эшче тариф комиссиясен үткәрү;

8) фикер каршылыкларын карау буенча комиссия утырышын үткәрү;

9) Идарә (коллегия) утырышы көн тәртибен дәүләт комитетының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару;

10) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул итү;

11) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау;

12) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча гариза төзү өлешендә дә:

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача формада һәм (яисә) Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге (алга таба – Бүлек) белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача һәм (яки) язмача мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, мөрәҗәгать итүченең язмача һәм электрон почта аша килгән мөрәҗәгатеннән тыш, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүченең электрон почта аша килгән мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң җиде эш көне узганчы җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүченең язмача мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон документ әйләнеше системасы аша (мөрәҗәгать итүченең әлеге системага тоташтырылган очракта) яисә почта аша (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән системага тоташтырылмаган очракта) язма мөрәҗәгатьне теркәгән көннән җиде эш көне узганчы җавап җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдимнең составы, формасы һәм тапшырыла торган документация һәм башка мәсьәләләр буенча консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдимне кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, электрон документ әйләнеше системасы, ТР БМАС, Татарстан Республикасы рәсми порталының интернет-кабул итү системасы аша, Портал аша әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә Дәүләт комитетына бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим кертә.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында бирелгән

тәкъдим.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүче портал аша электрон формада бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

Порталда авторизацияләнә;

Порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Административ регламентның 2.6.9 пункты таләпләренә туры китереп имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Портал аша Дәүләт комитетына җибәрелгән электрон эш. Электрон гариза бүлек белгече өчен файдалана алырлык була.

3.3.3. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече:

бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдимне кабул итә;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гаризаны беренчел эшкәртә һәм теркәү номерын биреп, кабул итү датасын күрсәтеп, аны электрон документ әйләнеше системасында терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

карау өчен Дәүләт комитеты рәисенә (алга таба – Рәис) юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдим килгән көнне башкарыла.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим тапшыру датасы:

а) турыдан-туры Дәүләт комитетына – гаризаны теркәү датасы;

б) почта (курьер) элемтәсе белән – почта юлламасында штемпель белән расланган, элемтә оешмасына почта юлламасын тапшыру датасы;

в) электрон формада – Дәүләт комитетының электрон документ әйләнеше системасында гаризаны теркәү датасы.

г) Портал – гаризага эш номенклатурасына һәм Порталдагы шәхси кабинетта чагылдырылган документларны тикшерү статусына ярашлы рәвештә номер бирелгән дата.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.3.4. Документларны кабул итүдән әлеге Административ регламентның 2.7.1 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Портал аша гариза биргәндә, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, мөрәҗәгать итүченең Порталдагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә, – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза электрон документлар әйләнеше системасы, ТР БМАС, Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша, Портал аша, почта аша, шул исәптән электрон почта аша электрон документлар рәвешендә, яисә «Интернет» челтәре аша кергәндә, – гариза һәм документлар Дәүләт комитетына килгән көнне яки, гариза һәм документлар Дәүләт комитетының эш вакыты тәмамланганнан соң килгән очракта, икенче эш көнендә. Гариза һәм документлар Дәүләт комитетына әлеге пунктта күрсәтелгән ысуллар белән ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта – Дәүләт комитетының ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң киләсе беренче эш көнендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язма) белдерү.

3.4. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы эшне ачу яки тәкъдимне караудан баш тарту һәм килгән тәкъдимне карау буенча эш буенча вәкаләтле кешене билгеләү турында карар кабул итү.

3.4.1. Рәис яки аны алмаштыручы зат бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдимне карый һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгеләү мәсьәләләре буенча эш итүче рәис урынбасарына яки аны алмаштыручы затка (алга таба – рәис урынбасары) карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карауга җибәрелгән бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдим.

3.4.2. Рәис урынбасары бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдимне карый һәм карау өчен бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карауга җибәрелгән бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тәкъдим.

3.4.3. Бүлек җитәкчесе яки аны алмаштырган зат бәяләрне (тарифларны)

билгеләү турында тәкъдимне карый.

Рәис урынбасары килешү буенча түбәндәге карарны кабул итә:

әлеге Административ регламентның 2.8.2.1 пунктында каралган нигезләр булганда , бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турында боерык яисә бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту һәм тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтару турында хат-белдерү проектын әзерли;

бүлек хезмәткәрләре арасыннан эш буенча вәкаләтле вәкилне билгеләү турында.

3.4.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында каралган документлар һәм материаллар закон нигезендә билгеләнгән срокларда тапшырылган очракта, җаваплы башкаручы, бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында эш ачу турында боерык проектын әзерли һәм бүлек башлыгына яисә аны алмаштыручы затка, юридик бүлек җитәкчесенә яисә аны алмаштыручы затка килештерү өчен җибәрә.

3.4.5. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын килештергәннән соң, рәис урынбасары тарафыннан әлеге документ килештерү өчен рәискә җиткерелә.

Рәис, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерыкны терки.

Эш буенча вәкаләтле вәкил бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу хакында хат-белдерү проектын әзерли һәм аны килештерү өчен – бүлек башлыгына, имзалау өчен рәис урынбасарына юллый.

3.4.6. Гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече хат-белдерүне теркәп, аны мөрәҗәгать итүчегә электрон документлар әйләнеше системасы, тапшыру турында хәбәр белән почта аша, шул исәптән электрон почта аша электрон документлар формасында яки «Интернет» челтәре аша җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе:

бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы эшне ачу турында боерык бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы гариза теркәлгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча чыгарыла.

хат-белдерү җайга салынулы оешмага бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшне ачу турындагы боерык теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

3.4.7. Әлеге Административ регламентның 2.8.2.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, эш буенча вәкаләтле зат бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту турында хат-белдерү проектын әзерли һәм аны килештерү өчен бүлек җитәкчесенә, имзалау өчен рәис урынбасарына җибәрә.

Гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече хат-белдерүне теркәп, аны мөрәҗәгать итүчегә электрон документлар әйләнеше системасы, тапшыру турында хәбәр белән почта аша, шул исәптән электрон почта аша электрон документлар формасында яки «Интернет» челтәре аша җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура бәяләр (тарифлар) билгеләү

турында гариза теркәлгәннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту турында хат-белдерү һәм җайга салу оешмасына юллау.

3.5. Җайга салу ысулын сайлау турында карар кабул итү.

3.5.1. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында тариф эшен ачу турында карар кабул ителгән очракта, эш буенча вәкаләтле вәкил тәкъдим ителгән материалларны, җайга салу оешмасы тәкъдимен исәпкә алып, Бәяләр формалаштыру нигезләрендә каралган, кулланыла торган ысулны билгеләү максатында тикшерә.

Тарифларны җайга салу ысулын бүлек җитәкчесе яки аны алмаштырган зат һәм рәис урынбасары белән килештерелә.

Бүлекнең җаваплы башкаручысы җайга салу ысулын сайлау турында боерык проектын әзерли һәм килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура җайга салу ысулын сайлау турында гариза алынган көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: җайга салу ысулын сайлау һәм аны килештерү турында боерык проекты.

3.5.2. Гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече җайга салу ысулын сайлау турында боерыкны терки.

Җаваплы башкаручы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җайга салу кагыйдәләренең (алга таба – Җайга салу кагыйдәләрен) 26 пунктына ярашлы рәвештә тапшыру турында хәбәр итеп, җайга салына торган оешмага почта аша җайга салу ысулын сайлау турында боерык җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура җайга салу ысулын сайлау турында карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: җайга салына торган оешмага җибәрелгән, тарифларны җайга салу ысулын сайлау турында боерык.

3.6. Тулы булмаган документлар пакеты тапшырылган очракта, эш буенча вәкаләтле вәкил тәкъдимне экспертизалау өчен кирәкле документлар һәм материаллар буенча гариза төзи. Мондый мәгълүматларны тапшыру вакыты җайга салу органы тарафыннан билгеләнә, әмма 7 эш көненнән дә ким була алмый.

Процедура нәтиҗәсе: җайга салына торган оешма адресына җибәрелгән гариза.

3.7. Җайга салынулы оешмалар тарафыннан бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тапшырылган тәкъдимне анализлау барышында бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимне тәгаенләштерү зарурлыгы барлыкка килсә, эш буенча вәкаләтле зат өстәмә белешмәләр сорату турында гариза төзи, шул исәптән җайга салынулы оешма тарафыннан алдагы җайга салу чорында фактта тотылган чыгымнарны раслый торганнарын да. Мондый мәгълүматларны тапшыру вакыты җайга салу органы тарафыннан билгеләнә, әмма 7 эш көненнән дә ким була алмый.

Процедура нәтиҗәсе: җайга салына торган оешма адресына җибәрелгән гариза.

3.8. Бәяләрне (тарифларны) исәпләү һәм җайга салына торган оешмага

таныштыру өчен җибәрү.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эш буенча вәкаләтле вәкил, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында кергән тәкъдимне анализлау нәтиҗәсен исәпкә алып, тарифлар исәпләү (тариф) параметрларын билгеләү тәртибенә төзәтмәләр кертә, аның нәтиҗәләрен җылылык энергиясенә бәяләр (тарифлар) исәпләренә эксперт бәяләмәсендә чагылдыра, ул бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшкә теркәлә.

Процедура нәтиҗәсе: тарифларны исәпләү һәм җайга салына торган оешмага танышу өчен җибәрү.

3.9. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында килгән тәкъдимне экспертизалау.

Эш буенча вәкаләтле зат бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимгә бәяләрне (тарифны) исәпләгәндә исәпкә алынган чыгымнарның нигезле булу-булмавы, бәяләрне (тарифларны) исәпләү параметрларын билгеләүнең төгәл булу-булмавы өлешендә экспертиза уздыра, аның нәтиҗәләрен җылылык энергиясенә бәяләр (тарифлар) исәпләмәсе бәяләмәсендә (алга таба – бәяләмә) чагылдыра, анысы бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшкә теркәп куела. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында килгән тәкъдимне экспертизалау бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимне карау турында эксперт нәтиҗәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

Дәүләт комитетының эксперт бәяләмәсе Җайга салу кагыйдәләренең 29 пунктына ярашлы рәвештә кирәкле мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

Дәүләт комитетының эксперт бәяләмәсе бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы эшне ачу турындагы эшкә теркәлә.

Эш буенча вәкаләтле эксперт бәяләмәсе проектын әзерли һәм килештерү өчен бүлек җитәкчесенә яки аны алмаштыручы затка, юридик бүлек җитәкчесенә яки аны алмаштыручы затка һәм рәис урынбасарына җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: эксперт бәяләмәсе, башкарылган исәпләмәләр буенча җайга салына торган оешмага җибәрү.

3.9.1. Эш буенча вәкаләтле вәкил җылылык челтәрләре милекчеләрен яисә башка законлы хуҗаларын Җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләрендә каралган җылылык челтәре оешмаларына кертү критерийларына туры китерү буенча җайга салына торган оешма тарафыннан тәкъдим ителгән документларны һәм материалларны анализлый.

Җылылык челтәрләре милекчесе яисә башка законлы хуҗасы җылылык челтәрләре милекчеләрен яисә башка законлы хуҗаларын Җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләрендә каралган җылылык челтәре оешмаларына кертү критерийларына туры килмәгән очракта, Дәүләт комитеты идарә (коллегия) утырышы нәтиҗәләре буенча әлеге Административ регламентның 2.8.2.2 пункты нигезендә бәяләр (тарифлар) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Бүлекнең җаваплы башкаручысы бәяләрне (тарифларны) билгеләүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли һәм килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бәяләр (тарифлар) билгеләү турында гариза теркәлгәннән соң 30 календарь көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләрне (тарифларны) билгеләүдән баш тарту турында боерык, Дәүләт комитеты идарәсе утырышы беркетмәсе.

3.10. Башкарылган алдан исәпләү нәтиҗәләре буенча эшче тариф комиссиясен үткәрү.

Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимне экспертизалау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар проектын, аңлатма язуын әзерли һәм эшче тариф комиссиясе утырышында карау өчен бүлек җитәкчесе, рәис урынбасары белән килештерә.

Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар проекты Дәүләт комитетының Эшче тариф комиссиясе утырышында «Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карарлар кабул итү регламентын һәм тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының башка карарларын кабул итү регламентын раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге 450/2021 номерлы боерыгында каралган тәртиптә һәм срокларда карала (алга таба – Карарлар кабул итү регламенты).

Карар проекты буенча фикер каршылыклары булмаганда, килешү кәгазе имзалана һәм карар проекты Дәүләт комитеты идарәсе утырышына чыгарыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында әзерләнгән карар проекты, аңлатма язуы, эшче тариф комиссиясе беркетмәсе, имзаланган килешү кәгазе.

3.11. Фикер каршылыкларын карау буенча комиссия утырышын үткәрү.

Карар проекты буенча фикер каршылыклары булганда, Дәүләт комитетына Регламент белән расланган карарлар кабул итү формасы буенча фикер каршылыклары фикер каршылыкларын карау буенча комиссия утырышында карау өчен тәкъдим ителә.

Каршылыклар Карарлар кабул итү регламентында каралган тәртиптә һәм срокларда Каршылыкларны карау буенча комиссия утырышында карала.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә утырышына чыгарылган карар.

3.12. Идарә (коллегия) утырышы көн тәртибен дәүләт комитетының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару.

Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольлек һәм теркәү бүлеге белгече идарә (коллегия) утырышының көн тәртибен «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Идарә (коллегия) утырышы көненә кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча башкарыла, анда бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул ителә.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә утырышына чыгарылган карар.

3.13. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар кабул итү.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар Дәүләт комитеты идарәсе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең эшчәнлек тәртибен һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында карау өчен мәсьәләләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 231 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт комитеты идарәсе (коллегиясе) утырышы нәтиҗәләре буенча бәяләрне (тарифларны) билгеләү буенча вәкаләтле эксперт (вәкаләтле экспертлар) тәкъдименнән аерылып торган бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар

кабул ителгән очракта, мондый карарның нигезләмәсе беркетмәдә (Җайга салу кагыйдәләренең 32(1) пункты) теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елның 20 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар өчен, шулай ук үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган аерым оешмаларга җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге җайга салынулы аерым эшчәнлек төрләренә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракта әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Дәүләт комитетына килгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт комитеты карары буенча әлеге вакыт 30 календарь көнгә озайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар, Дәүләт комитеты идарәсе утырышы беркетмәсе.

3.14. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.14.1. Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне дәвамында, әмма чираттагы җайга салу чорына кадәрге елның 21 декабреннән дә соңга калмыйча, тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге белгече:

күрсәтелгән карарга ярашлы рәвештә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән һәр җайга салына торган оешмага Портал аша, тапшыру турында хәбәр белән почта аша һәм электрон рәвештә күрсәтелгән карарның беркетмәсен (беркетмәдән өзекләр) теркәп, аның күчермәсен җибәрә. Әлеге пунктта күрсәтелгән материаллар шулай ук федераль башкарма хакимият органына тарифларны дәүләти җайга салу өлкәсендә гади почта юлламасы итеп һәм югарыда күрсәтелгән срокларда электрон рәвештә җибәрелә;

бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне дәвамында, әмма чираттагы җайга салу чорына кадәрге елның 21 декабреннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында беркетмәне теркәп, бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карарны урнаштыра.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру.

3.15. Техник хатаны төзәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта ярдәмендә яисә

электрон документ әйләнеше системасы, яисә Портал аша җибәрелә.

3.17.1. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече:

техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итү;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм, теркәлү номеры беркетеп һәм кабул итү көнен күрсәтеп, гаризаны электрон документ әйләнеше системасында терки;

мөрәҗәгать итүчегә кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

карау өчен Рәискә җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Гаризаны тапшыру датасы булып түбәндәгеләр тора:

а) турыдан-туры Дәүләт комитетына – гаризаны теркәү датасы;

б) почта (курьер) элемтәсе белән – почта юлламасында штемпель белән расланган, элемтә оешмасына почта юлламасын тапшыру датасы;

в) электрон формада – Дәүләт комитетының электрон документ әйләнеше системасында гаризаны теркәү датасы.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм тиешенчә җибәрелгән белдерү.

3.17.2. Рәис яки аны алмаштыручы зат техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм Рәис урынбасарына яисә аны алмаштыручы затка карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында карау өчен рәис урынбасарына юлланган гариза.

3.17.3. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм алга таба эшләү өчен бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: алга таба эшләү өчен бүлек җитәкчесенә җибәрелгән техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.17.4. Бүлек җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән вәкаләтле зат, кергән гаризаны караганнан соң, документларны дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында карый, әлеге Регламентта каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, шәхсән имзалатып, төзәтелгән документны бирә яисә почта аша, яисә электрон почта аша, яки электрон документ әйләнеше аша, яисә Портал аша техник хата булган документның оригиналын бүлеккә тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән, Портал аша яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша, электрон документ әйләнеше системасы аша һәм электрон рәвештә мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән җавап.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган Дәүләт комитеты рәисе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы тикшереп тору Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның әлеге Административ регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм Мөрәҗәгать итүчеләрнең Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләү.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт комитеты актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт комитетының еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә гаепле затларны җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук әлеге Административ регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты яисә Дәүләт комитетының дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә рәис кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә Монополиягә каршы федераль хезмәткә тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7

статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Интернет-кабул итү бүлмәсе, Портал аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Дәүләт комитетына алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә карала һәм Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6. Әлеге Администартив регламентның 5.5 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, Дәүләт комитетында гамәлгә ашырыла торган

гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Оешманың фирма бланкында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

______________________________

(инициаллары, фамилиясе)

Җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләү турында

## ТАРИФЛАР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА ГАРИЗА

Мөрәҗәгать итүче:________________________________________________________________

(Мөрәҗәгать итүче - юридик затның уставка ярашлы фирма атамасы)

Оешма реквизитлары:_____________________________________________________

(ИНН, КПП, ОКПО, ОКАТО, ОКОГУ)

Юридик адрес:_________________________________________________________

Почта адресы:___________________________________________________________

Оешма җитәкчесе:_____________________________________________________

(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

___________________________________________________________________________

Башкаручы_______________________________________________________________

(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

Элемтә өчен телефоннар, факс, электрон почта адреслары:

____________________________

Мөрәҗәгать итүченең тарифлар билгеләү өчен мөрәҗәгать итү нигезе:

___________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән таләп (җылылык энергиясенә тәкъдим ителә торган тарифлар дәрәҗәсе):

I яртыеллык ____________________________________________________________;

II яртыеллык
_____________________________________________________________________.

Җайга салу (төзәтмәләр кертү) чоры ___________________________________________

Кушымта: Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына тапшырылган материаллар реестры (битләрен нумерацияләп) __________ биттә.

Оешма җитәкчесе (тулы имза)

(оешма мөһере)

Дата

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

______________________________
(инициаллары, фамилиясе)

## ҖАЙГА САЛУ ЫСУЛЫН САЙЛАУ ТУРЫНДА ГАРИЗА

Мөрәҗәгать итүче:_________________________________________________________________
(Оешманың тулы атамасы)

Оешма реквизитлары:___________________________________________________
(ИНН, КПП, ОКПО, ОКАТО, ОКОГУ)

Юридик адрес:________________________________________________________

Почта адресы:________________________________________________________

Оешма җитәкчесе:__________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

Башкаручы___________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

Элемтә өчен телефоннар, факс, электрон почта адреслары:
____________________________

Җайга салынулы товар һәм хезмәт күрсәтү төрләре:____________________

Тарифларны җайга салу ысулы:
___________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________.

Җайга салу чоры ___________________________________________________

Тарифларны җайга салу ысулын сайлауның максатка ярашлылыгын нигезләү:
__________________________________________________________________________.
__________________________________________________________________________.
__________________________________________________________________________.

Оешма җитәкчесе (тулы имза)
(оешма мөһере) Дата

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитеты тарафыннан җылылык
белән тәэмин итү өлкәсендә
җайга салынулы бәяләр
(тарифлар) билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисенә
_______________________________
(инициаллар, фамилия)

Техник хата төзәтү турында
ГАРИЗА

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ____________________ №___ карарындагы хата турында хәбәр итәм, ул җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән.

Язылган:_______________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ___________________________________________________
Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган карарга тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ______________________________________________________________;
2. ______________________________________________________________;
3. ______________________________________________________________.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:
түбәндәге адреска документ җибәрү юлы белән: ____________________;
_____________________________________________ адресы буенча кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүегез турында үтенәм.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис<br>Груничев Александр Станиславович | 8 (843) 221-82-18 | кt@tatar.ru |
| Рәис урынбасары<br>Павлов Сергей Вячеславович | 8 (843) 221-82-04 | Pavlov.SV@tatar.ru |
| Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе Насыйрова Алсу Зимнур кызы | 8(843)221-82-41 | Alsu.Nasyrova@tatar.ru |
| Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе урынбасары Кубашева Эльза Энгелевна | 8 (843) 221-82-42 | Elza.Kubasheva@tatar.ru |
| Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе урынбасары Яруллина Роза Илдар кызы | 8 (843) 221-82-55 | Roza.Yarullina@tatar.ru |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге башлыгы<br>Салихов Фаил Фатыйх улы | 8 (843) 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |

Монополиягә каршы федераль хезмәт

Элемтә өчен телефон: 8 (499) 755-23-23, электрон адрес: delo@fas.gov.ru.